«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Васильево 3нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

Авторы: Шекаева Надия Фаязовна

Сыйныфтан тыш чара: Якташыбыз Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдиновның тормыш юлы, иҗаты.

“Мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес”

(Илдар Юзеев)

Васильево 3нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбенең туган тел һәм әдәбият укытучысы Шекаева Надия Фаязовна

Васильево, 2021

**Чараның максаты:**

- укучыларны якташыбыз  Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдиновның тормыш һәм иҗат юлы, шигырьләре белән таныштыру, аның шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү;
- туган төбәк язучыларының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- милли үзаң, югары әхлак сыйфатларын тәрбияләү

**Чараның барышы:**

1. **Укытучының кереш сүзе.**

- Исәнмесез, хөрмәтле кунакларыбыз , укытучылар, укучылар.

Яшел Үзән районы – татар халкына бик күп күренекле ул һәм кызлар бүләк иткән төбәк. **(Слайд 2)** Атаклы язучылар да, шагыйрьләр дә, төрле фән өлкәләрендә эшләгән абруйлы галимнәр дә аз чыкмаган бу яктан. Афзал Шамов, Идрис Туктар, Азат Вергазов, Шәриф Сайкин, Гомәр Саттаров, Резедә Төхвәтуллина, Рәшид Кәлимуллин кебек атаклы кешеләрнең исемнәрен күпләр белә!

Күренекле артистлар: Усман Әлмиев, Рәшид Сабиров, Резедә Төхвәтуллина, Йосыф Гыйззәтуллин; Медицина университеты ректоры, профессор- Наил Хәбибулла улы Әмиров; филология фәннәре докторлары, профессорлар: Нәзим Габдрахман улы Ханҗафаров  һәм Гомәр Фәиз улы Саттаров.

Менә тагын аерым игътибарга лаек ике шәхес: болар- безнең бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйри һәм искиткеч талантлы рәссам Константин Васильев. **(Слайд 3)**

Яшел Үзәннең музыкаль талантлары турында сөйли башласак, ТР композиторлар Союзы рәисе  Рәшид Фәһимович Кәлимуллин да искә алмый мөмкин түгел. Ул 1957 елда Яшел Үзәндә туган, 3 нче мәктәпне тәмамлаган.

Яшьтән үк булдыклы бала-ике ел эчендә музыка мәктәбен тәмамлаган. Аннан соң музыка училищесы, консерватория.

Казан консерваториясе ректоры булган Рубин Кәбир улы Абдуллин да 1950 елда Яшел Үзәндә туа, шунда укый.

Татарстанның халык артисты, татар операсына нигез салучыларның берсе, легендар җырчы Усман Әлмиев та 1915 елда Яшел Үзән районы Акъегет авылында дөньяга килә. Усман Әлмиев- опера сәнгатен генә түгел, татарларда эстрада җырын да популярлаштыра башлаучы.

Сара Садыйкованың ата-анасының туган авылы – Айдар.

Артистка Сәхибҗамал Иделленең (Волжская) тамырлары да Яшел Үзәннең Тугач авылында.

Габдулла Тукайның апасы соңгы көннәрен Васюково авылында яшәгән, шунда вафат булган.

Яшел Үзән җиреннән мондый олуг шәхесләрнең чыгуы юкка гына түгелдер. Моны төбәкнең искиткеч гүзәл табигате, суларының шифалылыгы, һавасының сафлыгы белән аңлатырга кирәктер. Мондый урында яшәгән кешеләрнең күңелләре дә саф, киң һәм иркен була. Бары шундый кешеләр генә - илгә үз халкы өчен җан атучы, талантлы шәхесләр .

Кичәбезнең төп герое- Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдинов**.(Слайд 4)** Исән булса, ул да безнең арада утырыр иде, мөгаен. Кызганычка каршы, 2018 нче елда Равил ага Сәйфетдинов безнең арадан китте. Татарстанның атказанган укытучысы , Россиянең мәгариф отличнигы, Хезмәт ветераны Равил Гарәветдин улының яшүсмер еллары һәм гомеренең күп өлеше Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында уза.

Аның тормыш юлын, иҗатын өйрәнү бүгенге көндә актуаль. Беренчедән, ул - безнең якташыбыз. Икенчедән, аның шигырьләре яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный. Бу шигырьләр бүген яңача, яңа мәгънә төсмерләре, яңа эчтәлек белән яңгырыйлар. “Һәрбер олы, һәрбер якты хыял - максатларның кыскасы, нигезе – хезмәт икән. Шул хыял - максатка ирешү юлында кеше үз намусына, үз вөҗданына каршы бармаска тиеш икән. Без

бер нәрсәгә ачык төшендек: күңел ятарлык, кеше тормышын бизәрлек һөнәр тапкан кеше бәхетле була, андый кешене бәхет үзе эзли". Бу юллар тагын бер якташыбыз М.Хәсәновның "Диас, Ильяс һәм робот МИАЗ" исемле хикәясеннән. Бу юллар Р. Сәйфетдиновның тормыш юлына, эшчәнлегенә туры килә.

Хәзер сүзне укучыларыбызга бирәбез.( Укучылар чыгыш ясый)

**1 нче укучы.**

**Равил аганың бала чагы, студент еллары турында сөйли.**

- Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 елның 14 октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. **(Слайд 5)** Аның бала чагы дәһшәтле сугыш елларына туры килә. Бу елларның авырлыгын, кырыслыгын аның үзенә татырга туры килә. Әтисе сугыш кырында ятып кала. Әнисе колхоз эшеннән бушамый. Шундый авыр шартларда да Равил тәрбияле, кешелекле булып үсә. Йорттагы хуҗалык эшләренең күбесен ул башкара, белемен дә күтәрә. Урта мәктәпне бетергәч, җиде фәннән имтихан тапшыра. Конкурста бер урынга җиде кеше була. Бу сынауны уңышлы үтеп, ул Казан дәүләт университетына укырга керә.

1956—1961 елларда Казан дәүләт университетында укый. **(Слайд 6)** Монда уку елларында үзен актив студент буларак күрсәтә : төрле кичәләрдә катнаша, шигырьләр иҗат итә. Ул Т. Галиуллин, Х. Миңнегулов, М.Усманов, И.Таһиров, Ф. Йосыпов, Н. Хисамов, Р.Кутуевлар белән бергә укый. Җәйге каникулларда алар чирәм җирләрдә эшлиләр. Равил абыйны " Чирәм җирләрне үзләштергәне өчен " медале белән бүләклиләр**. (Слайд 7)**

**Укытучы.**

- Балалар, Равил аганың шушы елларда язылган берничә шигырен тыңлап алыйк әле. ( Берничә укучы шигырь сөйли)

1. **"Этюд"**
   Беренче кат
   Болынга көтү килде,
   Уйнатып сигнал бирде.

Яңгырады еракларга
Күптән көтелгән моңнар.
Тыңлады һәм кабатлады
Ул моңнарны киң кырлар.
Тау өстендә кояш көлде,
Күктә тургай сайрады,
Йомшак җилләр исеп үтте,
Тәмле исләр таралды. (1957)

2. **“ Дала юлында”**
Дулкынлана зәңгәр күк астында
Алтын агым- бодай диңгезе;
Әнә совхоз- тиздән карталарда
Яктырачак шәһәр нигезе.
Чирәм җирләр!
Чорыбызга тиң сез,
Нинди киң сез,
Кабатлыйлар йөрәк тибешемне
Сезнең кырлардагы моторлар.  (1958)

3. **“Ай нигә үрти”**
Тимер шарчык тапты Басыйр,
Җепкә бәйләде;
Кулындагы шарчык
Зыр-зыр әйләндә.
Шар ычкынып тәлинкәне
Ярып та атты.
Әни күрмәсен дип Басыйр
Чыгып та чапты.
Күктә ай белгән! Басыйрны үртәде көлеп,
Яртысы ватылып төшкән
Тәлинкә кебек. (1961)

**2 нче укучы**. **Равил Сәйфетдиновның педагогик эшчәнлеге.**

- Равил Сәйфетдинов педагогик практиканы Казанның 89 нчы татар мәктәбендә үтә. Ул үткәргән татар теле дәресләренә югары бәя бирелә. Кышкы каникулларда авылларда милләтебез тарихы турында кызыклы лекцияләр укып йөри.

Университетны тәмамлагач, аны Самара өлкәсендәге Гали авылы мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр**.(Слайд 8)** Ул монда ике ел эшли: татар,

рус, немец телләрен укыта. Пушкин, Евтушенко, Гёте, Гейне шигырьләрен татарчага тәрҗемә итә. Шушы мәктәптә ул укучылар күңеленә юл табарга өйрәнә. Авыл халкы, укучылар аны бик хөрмәт итәләр.

**3 нче укучы**. **Равил Сәйфетдинов туган авылы- Мулла Илендә.**

-1963 нче елда Р.Сәйфетдинов Мулла Иленә кайта , һәм шушы көннән аның бөтен калган гомере туган авылында уза**.(Слайд 9)** 1968 нче елда аны директор урынбасары итеп куялар, 1971 нче елдан мәктәп директоры итеп билгелиләр. Ул 2000 нче елга кадәр директор булып эшли. **(Слайд 10)** Җитәкче булса да, ул гомере буена укытучы булып кала. Һәр дәресенә әзерләнеп керә, укучылар аның дәресләрендә мавыгып, кызыксынып укыйлар. Татар теленнән, әдәбиятыннан олимпиадаларда укучылары призлы урыннар яулыйлар. Равил Гарәфетдинович кырыслыкны ягымлы юмор белән аралаштыра белә.

Равил ага әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнүен дә дәвам итә: яңадан-яңа шигырьләр иҗат итә.

(Укучылар шигырь сөйлиләр)

**4 нче укучы. ”Гыйлем генә нурлый бәндәне”**

Аллаһының нигъмәтләре чиксез:
Протоннар, галактикалар...
Иң-иң хикмәтлесе- тик кешеләр,
Аң-акылга ия тик алар.
Җиргә кеше итеп тудырганга
Көн-төн рәхмәт укы Раббыңа.
Яшисең син ап-ак күңел белән,
Хакның сүзен әйтеп халкыңа.
Тынмый арттырасың гыйлемеңне,
Хак дин белән бәйләп фәннәрне.
Гыйлем генә ача хакыйкатьне,
Гыйлем генә нурлый бәндәне. (1969)

**5 нче укучы. ”Май яме”**

Киләчәккә-

Гомерлеккә, мәңгелеккә

Җиргә тыныч яшәү ямен бүләк итеп,

Май кояшы

Балкый чиксез зәңгәрлектә,

Кешеләргә алтын керфекләрен сирпеп.

Тыелгысыз

Яшәү дәрте кайный җирдә,

Гөлләр гөрләп якты күккә үреләләр.

Тургай җырын

Тыңлый-тыңлый , йомшак җилдә,

Яшел ужым дулкыннары йөгерәләр.

Яфрак туе!

Яшеллек һәм яшьлек туе!

Тереклеккә көч бирүче тылсымлы ай.

Кыз-егетләр килеп йөри көннәр буе,

Туксан яшьлекләр дә яшәрәләр бугай.

Бар күңелләр

Якты өмет белән тула .

Рухландыра алдагысы бөек эшләр,

Замананы ышанычлы әйдәп бара

Сугышларны мәңге булдырмаслык көчләр. (1983)

**6 нчы укучы. “Татар теле”**

Латин теле кебек үле түгел

Татар теле.

Рецептларда түгел, көнкүрештә

Яши тере.

Урыс теле кебек бөек түгел

Татар теле.

Бөек телләр үлгәндә дә ләкин

Бетмәс түлке. (1996)

**7 нче укучы. Равил Сәйфетдиновның иҗтимагый эшчәнлеге.**

Равил Гарәфетдинович авыл тормышында, җәмәгать эшләрендә дә кайнап яши.**(Слайд 11)** Район Советы депутаты буларак, авылларга асфальт юл салдыруга зур өлеш кертә. Үзенә йөкләнгән барлык вазифаларны да җиренә җиткепреп башкара: агитаторлар җитәкчесе, пропагандист, авыл Советы рәисе урынбасары, Иптәшләр Суды рәисе, комсомол секретаре, " Белем җәмгыяте" лекторы... Кичке мәктәптә авыл яшьләрен укыту-тәрбияләүгә дә зур көч куя.

Ул район һәм Мулла Иле авылы тарихын өйрәнүгә зур хезмәт куя. Мәктәптә "Авыл тарихы" музеен оештыра. Аның тырышлыгы белән авылның 750 еллык юбилеен республика күләмендә зурлап билгеләп үтәләр.

Равил ага 2008 нче елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр Мулла Иле авылында имам-хатыйб вазифаларын да башкара.**(Слайд 12)** "Һәрбер дини чарага ул олы иман, зур тырышлык белән әзерләнә", - диләр аның турында авылдашлары. Мәчет каршындагы мәктәптә балаларга дин сабагы да укыта. "Мәңгелеккә килдем дип эшлә, иртәгә үләм дип гыйбадәт кыл", - дип яши ул. 2017 елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

**Укытучы.**

- Равил Гарәфетдинович Сәйфетдиновның эшчәнлеге бәяләнмичә калмый. СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы, " Татарстанның атказанган укытучысы ", "Россиянең мәгариф отличнигы" дигән мактаулы исемнәр бирелә, "Хезмәт ветераны" медале белән бүләкләнә.**(Слайд 13)**

2018 нче елның 10 нчы февралендә ул вафат була.

Мулла Иле халкы үзе олы тормышка чыгарган, соңгы тору урынын да шушында сайлаган милләт җанлы Равилен онытмый һәм киләчәктә дә онытмас, дип ышанабыз.**(Слайд 14)** Аның шәхесе, ул тудырган шигырьләр һәрвакыт халык күңелендә сакланыр. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.